| УКАЗ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>УКАЗЫ |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында**

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Әлки районының Иске Үргәагар авылы;

Сарман районының Кормаш авылы;

Тәтеш районының Кече Тормы авылы;

Тукай районының Останково авылы;

Теләче районының Лесной поселогы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Яңа Үзи авылындагы Адоратский урамы;

Апас районы Апас шәһәр тибындагы поселогының Киров урамы;

Яңа Чишмә районының Екатерина Бистәсе авылындагы Чокыр яны урамы;

Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылындагы Мәктәп урамы;

Балык Бистәсе районының Троицкий Урай авылындагы Почта урамы;

Саба районының Яулауташ авылындагы Җәлил урамы;

Саба районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогының Әбрар Кәримуллин урамы;

Ютазы районының Иске Урыссу авылындагы Чапаев урамы;

Казан шәһәренең Кадышево торак массивындагы «Промстройматериалы» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте;

Казан шәһәре Яңа Аракчино торак массивындагы Новостройка урамының 12 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Казан шәһәренең Оренбург Тракты урамындагы 128-151 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Алексеевск районының Урманасты Шонталысы авылы янындагы «Сөт Иле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте филиалы «Ясная Поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (Шонталы бүлекчәсе) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Буа районы Кайбыч авылы янындагы «Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Кайбыч районы Ульянково авылы янындагы «Ак Барс Кайбыч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (1 номерлы бригада) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Питрәч районы Татар Тау Иле авылы янындагы «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Питрәч районы Кибәч авылы янындагы «Золина Е.Н.» крестьян (фермер) хуҗалыгының яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны иткә сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 18 апрель
№ ПУ-392